ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта “(1 майдан алып 1 октябрьгә кадәрге чорда сезонлы (җәйге) кафеларда сыраны һәм сыра эчемлекләрен ваклап сатудан тыш)” сүзләрен өстәргә;
2) 5 пунктта “(ишегалларыннан)” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 27-ТРЗ